ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕСУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422158

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

Постановление Карар

«02» март 2023 ел № 57

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 22 декабрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында» 9 номерлы карарын үз көчен югалтты дип тану турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 декабрендәге 261-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән яктырту җайланмалары, электр лампалары, тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган калдыклар белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 22 декабрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында» 9 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының

рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлеге башкарма җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче: Р.Ш.Гафиятуллин